*Шәхесләр*

# Безнең юбиляр

## БЕРЕНЧЕ ҺӘМ ХӨРМӘТЛЕ РЕДАКТОР

Текст авторы **Олег ӘНДӘРҖӘНОВ**
Фото «Туган як» редакциясе архивыннан



«ЯШӘ ҖИРДӘ ЭЗ КАЛДЫРЫП, ЭЗЛӘРЕҢ СУЫНМАСЫН, КЫЛГАН ГАМӘЛЛӘРЕҢ ӨЧЕН ҮКЕНЕРЛЕК БУЛМАСЫН», — ДИП ҖЫРЛЫЙ ЯШЬ ҺӘМ ТАЛАНТЛЫ ҖЫРЧЫБЫЗ АЙРАТ САФИН. ӘММА ЛӘКИН, ҮПКӘГӘ БУЛМАСЫН, СҮЗЕМ ӨМЕТЛЕ ҖЫРЧЫ ТУРЫНДА ТҮГЕЛ, АНЫҢ ЙОЛДЫЗЫ ТАТАР ЭСТРАДАСЫ КҮГЕНДӘ БАЛКЫП ЯНАЧАК ӘЛЕ, АЛЛА КУШСА. МИН НИЖГАР ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫНДА ТИРӘН ЭЗ КАЛДЫРГАН, КЫЛГАН ГАМӘЛЛӘРЕ ӨЧЕН ҮКЕНЕРЛЕК БУЛМАГАН ХӨРМӘТЛЕ АКСАКАЛАБЫЗ, УЗГАН ГАСЫРНЫҢ ҮЗГӘРТЕП КОРУ ҖИЛЛӘРЕ БЕЛӘН ТАТАР МИЛЛИ ХӘРӘКӘТЕН ҺӘРЬЯКЛАП ҺӘМ ТӨРЛЕ ЮНӘЛЕШТӘ КУЗГАТЫП ҖИБӘРҮЧЕ, ХАЛКЫБЫЗ ҮЗАҢЫН АГАРТУЧЫ МИЛЛӘТПӘРВӘРЛӘР ПЛЕЯДАСЫНЫҢ СОҢГЫ МОГИКАННАРЫННАН САНАЛГАН РИФАТ ФАТЫЙХ УЛЫ ИБРАҺИМОВ ТУРЫНДА ЯЗЫП, АНЫ КИЛӘЧӘК БУЫНГА ҮРНӘК ИТЕП КҮРСӘТӘСЕМ КИЛӘ.

Мин Нижгар татарлары тормышында тирән эз калдырган, кылган гамәлләре өчен үкенерлек булмаган хөрмәтле аксакалабыз, узган гасырның үзгәртеп кору җилләре белән татар милли хәрәкәтен һәрьяклап һәм төрле юнәлештә кузгатып җибәрүче, халкыбыз үзаңын агартучы милләтпәрвәрләр плеядасының соңгы могиканнарыннан саналган Рифат Фатыйх улы Ибраһимов турында язып, аны киләчәк буынга үрнәк итеп күрсәтәсем килә. Икенчедән, агымдагы елда ул берничә мөһим һәм истәлекле даталарын билгеләп үтәчәк.

Мәсәлән, 5 майда Рифат Фатыйховичка 80 яшь тула. 7 декабрьдә аның иҗади хезмәт җимеше булган «Туган як» өлкә татарлары газетасына 25 ел. Ярты гасырлык хезмәт юлына, биографиясенә күз ташласак, тагын юбилейлы даталарын күреп алырга мөмкин. Мәсәлән, Шөбиледә укытучылар гаиләсендә туып, Кочко-Пожарның 7 еллык мәктәбен «с отличием» тәмамлавына 65 ел, ә Казан педагогия институтын шулай ук «с отличием» тәмамлавына — 55. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Рифат Фатыйхович 1954 елда Сергач педучилищесын да «с отличием» тәмамлый.

Язма героемның юбилейлы даталарына килгәндә, аның тагын бер мөһим һәм үрнәкле гомер бәйрәменә тукталып үтү үз-үзеннән сорала: хәләл җефете, гомерлек җан юлдашы Клара Газизовна белән парлашып гаилә коруларына быел 55 ел тула. Зөбәрҗәт туйлары аларның 16 июль көненә туры килә, чөнки 1960 елның нәкъ шул көнендә алар язылышканнар. Ә булачак хатыны белән Рифат Фатыйхович Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укыганда таныша һәм Татарстанның Мамадыш кызын үзе белән безнең Нижгар якларына алып кайта. Хезмәт юлларын алар ул вакытта барлык татар авылларын үз эченә алган Кзыл-Октябрь районында юллама буенча башлыйлар. Рифат абый Сафаҗай мәктәбенә директор итеп билгеләнә, ә Клара Газизовна мәктәптә һәм район мәгариф бүлегендә эшли. Уку-укыту учреждениесен тугыз ел уңышлы җитәкләгәннән соң, Рифат Фатыйховичны милли районның партия комитетына секретарь итеп эшкә алалар.

1975 елда язмыш аларны Сергачка китерә. Ичмасам, менә тагын бер түгәрәк дата — Ибраһимовларның шәһәргә күченеп яшәүләренә быел 40 ел. Рифат абый озак еллар Сергач шикәр заводында партоешма секретаре булып эшли. Ә үзгәртеп кору еллары башлану белән татар телендә өлкә иҗтимагый-сәяси газетасына җитәкче эзләгәндә, Рифат Фатыйховичны Сергачның «Коопунивермаг» дигән сәүдә предприятиесенең директор кабинетында табалар. Бу вакыйга, белгәнегезчә, 1990 елга карый. Ул заманда Клара Газизовна белән Рифат Фатыйховичның өч буй кызлары була инде. Хәзер алар барысы да үз тормышлары белән яши. Диляра, мәсәлән, Түбән Камада, Римма белән Гүзәл — Мәскәүдә. Өчесе дә югары уку йортларын тәмамлаган белгечләр һәм ягымлы әниләр. Бүген Ибраһимовларның биш оныклары һәм бер оныкчыклары бар.

Нәкъ менә шул 1990 елдан башлап, Рифат абыйның югары белеме, оештыру сәләте, тормышчан тәҗрибәсе, җан шөгыле булган крайны өйрәнүе татар җәмәгатьчелеге файдасында ачык чагылыш таба.

— Мин бит әле 1982 елда ук СССРның партия Үзәк Комитетына татар телендә газета чыгаруны сорап хат язган идем. Шуннан соң мине милләтчелектә гаепләделәр, ләкин эзәрлекләүләр булмады. Ә менә исем-фамилиямне карандашка алган булганнар күрәсең, чөнки Нижгар татарлары өчен газета оештыру мәсьәләсе калкып чыккач, мине тиз эзләп таптылар һәм милли периодик басманы булдыру эшен йөкләделәр, — ди